РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
АДАВ-ТУЛУМБАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АДАВ-ТОЛЫМБАЙ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

«07» май 2025　　　　　　　　　　　　　　　　№ 2-96

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2003 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, муниципаль норматив актны кануннарга туры китерү максатларында, Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге Советының 2019 елның 26 февралендәге 1-58 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (12.02.2020 № 1-76, 20.10.2020 № 2-4, 23.11.2020 № 1-6, 22.12.2020 № 1-8, 22.06.2021 № 3-22, 15.07.2021 № 1-23, 06.02.2023 № 2-63, 07.04.2023 № 2-66, 08.06.2023 № 1-68, 26.06.2023 № 1-70, 22.03.2024 №1-79, 18.11.2024 № 1-87, 18.04.2025 № 2-94 карарлары ред.) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 9 бүлектә:

9.3 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.3) Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе бетерелгәндә, аның шәхси эше саклауга җирле үзидарә органына, җирле үзидарәнең юкка чыгарылган органнары функцияләре тапшырылган муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенә, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенә яисә аларның хокукый варисларына тапшырыла.».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми басылып чыккан мизгелдән законлы көченә керә (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылырга тиеш (http://buinsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы
Адав-Толымбай авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　　　А.Ф.Әхмәтҗанов